ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» сентябрь 2020 ел № 301

«Контузлы нефть ятмасын төзекләндерү.
Мультифаза насослары мәйданы»
объекты буенча аның составында ызанлау проекты
белән планлаштыру проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьясы нигезендә, «Теплогазпроект» ЖЧҖенең 2020 елның 08 сентябрендәге 611 номерлы язма мөрәҗәгатен карап, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Теплогазпроект» ЖЧҖгә «Контузлы нефть ятмасын төзекләндерү. Мультифаза насослары мәйданы» объекты буенча аның составында ызанлау проекты белән планлаштыру проектын әзерләргә тәкъдим итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, ТКХ, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә физик һәм юридик затлардан «Контузлы нефть ятмасын төзекләндерү. Мультифаза насослары мәйданы» объекты буенча аның составында ызанлау проекты белән планлаштыру проектын әзерләү һәм карап тоту тәртибенә тәкъдимнәр кабул итәргә һәм карарга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**